Региональная олимпиада по родным (татарскому, чувашскому, мордовскому) языкам и литературе
ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК
Региональный этап
2025-2026 учебный год

ОТВЕТЫ
8 КЛАСС

I. Бу юллар кайсы әсәрдән ? Авторын, исемен языгыз. (10 балл)

Әллә шул чакта ,әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Я Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Еге , үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы, хәлсезләнеп, мендәр читенәавып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды ...

Әмирхан Еники. “Кем җырлады”

II. Әсәрләрнең авторларын языгыз. (10 балл)

А) «Идегәй» - халык авыз иҗаты
Ә) «Җидегән чишмә» - Гомәр Бәширов
Б) «Кораб» - Дәрдемәнд
В) «Тапшырылмаган хатлар» - Гадел Кутуй
Г) «Каеннар сары иде» - Хәсән Туфан

III. Үзегез укыган әсәрләр арасыннан 2 шигырь, 2 әдәби әсәрнең исемен һәм авторын языгыз (10 балл).

_____
_____
_____
_____
_____
_____

IV. Бирелгән сүзләрне җыеп, шигырь юллары төзегез. Авторын, шигырьнең исемен билгеләгез. (10 балл)

Тау башына салынгандыр, безнең авыл,
Бер чишмә бар якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән.
(Габдулла Тукай, “Туган авыл”)

V. Иҗади бирем (10 балл).

Белем алу – энә белән кое казу *(татар халык мәкале).*

Сез бу фикер белән килешәсезме? Мәкальдә ни өчен шулай дип әйтелгән дип уйлыйсыз? Үз фикерегезне языгыз.

Эшнең эчтәлегеннән, җөмләләрнең дөрес төзелешеннән чыгып бәяләнә.